Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXXIX-3**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 19 июле

2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексы, «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дип билгеләргә.

2. Карарның 1 пункты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов